ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Ленина ул., д.48 “а”
пгт. Рыбная Слобода, 422650

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Ленин урамы, 48 “а”нче йорт,
Балык Бистәсе, 422650

Тел.: (8-4361) 2-34-16, 2-26-86, факс: (8-4361) 2-31-18. эл.адрес: Rs.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# КАРАР

2016 елның 30 июне штп. Балык Бистәсе № 70

Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең
административ регламентларын раслау
турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында»02.11.2010 ел, №880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында» 21.06.2016 №96пи карарын исәпкә алып, карар бирәм:

1. Раслау

1.1. Торак урынны үзгәртеп коруга һәм (яисә) яңадан планлаштыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (1 нче кушымта).

1.2. Социаль наем шартнамәсе буенча гражданинга муниципаль милектә булган торак урыны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта).

1.3. Торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган (торак) бинага күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәрнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (3 нче кушымта).

1.4. Адресларны бирү, үзгәртү ,гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт

күрсәтүнең административ регламенты (4 нче кушымта).

1.5. Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (5 нче кушымта).

1.6. Социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урыннарын алмашу документларын рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (6 нчы кушымта).

1.7. Элек хосусыйлаштырылган торак урыннарны муниципаль милеккә кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (7 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының 01.04.2014 ел, №8 карарының үз көчен югалтуын тану, 08.09.2015 ел, №38 карар

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитетының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе поселогы штп., 48А йорт, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитетының Интернет-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкчесе М. М. Вәлиев